КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 30 декабрь г.Казань № 1221

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Театр сәнгате өлкәсендә Марсель Сәлимҗанов исемендәге республика премиясе турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1087 нче карары белән расланган Театр сәнгате өлкәсендә Марсель Сәлимҗанов исемендәге республика премиясе бирү буенча конкурс комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Театр сәнгате өлкәсендә Марсель Сәлимҗанов исемендәге республика премиясе турында» 2014 ел, 31 декабрь, 1087 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 17 июль, 572 нче; 2019 ел, 6 сентябрь, 796 нчы; 2022 ел, 2 сентябрь, 945 нче; 2023 ел, 23 май, 628 нче; 2023 ел, 3 ноябрь, 1415 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Театр сәнгате өлкәсендә Марсель Сәлимҗанов исемендәге республика премиясе бирү буенча конкурс комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан Р.А.Таҗетдиновны чыгарырга;

комиссия составына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры» дәүләт бюджет учреждениесенең сәнгать җитәкчесе, «Әкият» татар дәүләт академия курчак театры» дәүләт бюджет учреждениесенең сәнгать җитәкчесе Илгиз Газинур улы Зәйниевны кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин